# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ «БИКЛӘН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ» МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ

## КАРАР

№ 10/2

«22» апрель 2021 ел

**2020нче ел өчен Биклән авыл җирлеге бюджеты үтәлеше турында хисап**

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Биклән авыл җирлеге Башкарма комитеты Җитәкчесене Сәхбеев М.Ш. «2020 ел өчен Биклән авыл җирлеге бюджеты үтәлеше турында хисап» хакында мәгълүматын тыңлап фикер алышканнан соң, муниципаль берәмлек Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. 2020 ел өчен Тукай муниципаль районы районы Биклән авыл җирлеге бюджеты үтәлеше турында хисапны керемнәр буенча 8994,55 мең сум, чыгымнар буенча 9221,30 мең сум күләмендә түбәндәге күрсәткечләр белән расларга:

- 2020 ел өчен Биклән авыл җирлеге бюджеты кытлыгын финанслау чыганаклары буенча әлеге карарга 1 кушымта нигезендә.
- 2020 ел өчен Биклән авыл җирлеге бюджеты керемнәре буенча әлеге карарга 2 кушымта нигезендә.
- 2020 ел өчен Биклән авыл җирлеге бюджеты чыгымнарының ведомство структурасы буенча әлеге карарга 3 кушымта нигезендә.
- 2020 ел өчен Биклән авыл җирлеге бюджетының бюджет ассигнованиеләрен бүлекләр һәм бүлекчәләр, максатчан статьялар һәм чыгымнар төрләре буенча бүлүнең функциональ структурасы буенча әлеге карарга 4 кушымта нигезендә.
- 2020 ел өчен Биклән авыл җирлеге бюджетының бюджет ассигнованиеләрен максатчан статьялар (муниципаль программалар һәм эшчәнлекнең программадан тыш юнәлешләре) чыгымнар төрләре төркемнәре, бюджетлар чыгымнары классификациясе бүлекләре һәм бүлекчәләре буенча бүлүне әлеге карарга 5 кушымта нигезендә.

2. Әлеге карарны авыл җирлегендә, мәгълүмати стендларда урнаштырырга.

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында һәм Тукай муниципаль районының рәсми сайтында «авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштырырга.

4. Әлеге карар халыкка игълан ителгәннән соң, законлы көченә керә.

Биклән авыл җирлеге Башлыгы,
Совет Рәисе М.Ш.Сәхбеев